**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 25 декабрендәге 4655 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 18 гыйнварындагы 100 номерлы «Учреждениеләргә үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыра торган муниципаль учреждениеләр, оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итә торган хезмәтләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтүче муниципаль учреждениеләрнең һәм социаль-мәдәни өлкә учреждениеләренең оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итә торган хезмәтләрнең хезмәткәрләренә 2026 елның 1 гыйнварыннан хезмәт хакын күтәрү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 18 гыйнварындагы 100 номерлы «Учреждениеләргә үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыра торган муниципаль учреждениеләр, оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итә торган хезмәтләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 27 июнендәге 2023 номерлы, 2022 елның 26 декабрендәге 4629 номерлы, 2024 елның 26 гыйнварындагы 243 номерлы, 2024 елның 19 июлендәге 3046 номерлы, 2024 елның 15 августындагы 3364 номерлы, 2024 елның 29 ноябрендәге 4947 номерлы, 2025 елның 10 февралендәге 311 номерлы, 2025 елның 12 мартындагы 663 номерлы, 2025 елның 14 маендагы 1469 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы кушымтадагы «Хезмәткәрләрнең окладын формалаштыру тәртибе» дигән II бүлекнең 1 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1 нче таблица

**Оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итүче җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәтләрдәге хезмәткәрләрнең вазифалары һәм вазифаи окладлары исемлеге**

| № т/б | Вазифа атамасы | Вазифаи оклад, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Бухгалтер | 32500 |
| 2 | Документлар белән эшләүче белгеч | 32500 |
| 3 | Инженер | 32500 |
| 4 | Җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча белгеч | 32500 |
| 5 | Икътисадчы | 32500 |
| 6 | Әйдәүче бухгалтер | 34400 |
| 7 | Әйдәүче бухгалтер-ревизор | 34400 |
| 8 | Документлар белән эшләүче әйдәүче белгеч | 34400 |
| 9 | Әйдәүче инженер | 34400 |
| 10 | Әйдәүче инженер-программист | 34400 |
| 11 | Әйдәүче белгеч | 34400 |
| 12 | Кадрлар буенча әйдәүче белгеч | 34400 |
| 13 | Җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча әйдәүче белгеч | 34400 |
| 14 | Әйдәүче икътисадчы | 34400 |
| 15 | Әйдәүче эксперт | 34400 |
| 16 | Әйдәүче юрисконсульт | 34400 |
| 17 | Сатып алулар буенча өлкән белгеч | 34400 |
| 18 | Сектор мөдире | 39300 |
| 19 | Төркем башлыгы урынбасары/бүлек башлыгы урынбасары | 39300 |
| 20 | Төркем башлыгы/бүлек башлыгы | 44519 |
| 21 | Баш бухгалтер урынбасары | 44519 |
| 22 | Баш бухгалтер | 51200» |

1.2. 1 номерлы кушымтадагы «Хезмәткәрләрнең окладын формалаштыру тәртибе» дигән II бүлекнең 2 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2 нче таблица

**Учреждениеләргә үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтә торган муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазифалары атамалары һәм вазифаи окладлары исемлеге**

| №<br>т/б | Вазифа атамасы | Вазифаи оклад, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Администратор | 32500 |
| 2 | Архив хезмәткәре | 32500 |
| 3 | Бухгалтер | 32500 |
| 4 | Инженер | 32500 |
| 5 | Әйдәүче бухгалтер | 34400 |
| 6 | Документлар белән эшләүче әйдәүче белгеч | 34400 |
| 7 | Әйдәүче инженер | 34400 |
| 8 | Әйдәүче инженер-программист/әйдәүче белгеч | 34400 |
| 9 | Әйдәүче инженер-смета төзүче | 34400 |
| 10 | Сатып алулар буенча әйдәүче белгеч | 34400 |
| 11 | Кадрлар буенча әйдәүче белгеч | 34400 |
| 12 | Әйдәүче икътисадчы | 34400 |
| 13 | Әйдәүче эксперт | 34400 |
| 14 | Әйдәүче юрисконсульт/әйдәүче юрисконсульт-эксперт | 34400 |
| 15 | Әйдәүче челтәр аналитигы | 34400 |
| 16 | Әйдәүче аналитик | 34400 |
| 17 | Мәгълүматны техник яктан яклау буенча әйдәүче белгеч | 34400 |
| 18 | Әйдәүче программист-эшләүче | 34400 |
| 19 | Бүлек башлыгы урынбасары | 36440 |
| 20 | Сектор мөдире/баш белгеч | 37722 |
| 21 | Сатып алулар (контракт хезмәте) учреждениесе бүлекчәсе җитәкчесе/хезмәт башлыгы | 39300 |
| 22 | Мәгълүмати системалар белән идарә итү бүлеге башлыгы | 39300 |
| 23 | Бүлек башлыгы | 39300 |
| 24 | Участок башлыгы/хезмәт башлыгы | 39300 |
| 25 | Баш инженер | 44843 |
| 26 | Цифрлаштыру буенча директор урынбасары | 44843 |
| 27 | Директор урынбасары | 44843 |
| 28 | Директорның беренче урынбасары | 44843 |
| 29 | Директор/идарәче директор | 54239» |

1.3. 1 номерлы кушымтаның «Социаль характердагы түләүләр һәм башка түләүләр, аларны билгеләү тәртибе һәм шартлары» дигән V бүлегенең 5 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«5 таблица

| №<br>т/б | Өстәмә матди ярдәм төре | Өстәмә матди ярдәм күләме |
|---|---|---|
| 1 | Бала туу уңаеннан (һәр балага) | Илле мең сум |
| 2 | Баланы уллыкка (кызлыкка) алу уңаеннан (һәр балага) | Илле мең сум |
| 3 | Хезмәткәрнең юбилей яисә башка истәлекле датасы уңаеннан:<br>- хатын-кызлар өчен – 50, 55 яшь;<br>- ирләр өчен – 50, 60 яшь;<br>- Татарстан Республикасы территориясендә җирле хакимият органнарында һәм муниципаль | Билгән вазифа буенча бер оклад |

| № т/б | Өстәмә матди ярдәм төре | Өстәмә матди ярдәм күләме |
|---|---|---|
| | органнарда, Татарстан Республикасы законы нигезендә җирле хакимият һәм идарә органнарында, муниципаль учреждениеләрдә теләсә нинди вазифаларда 20, 25 ел эш стажы (2005 елга кадәр – Казан шәһәренең тиешле дәүләт органнарында);<br>- 50 ел хезмәт стажы | |
| 4 | Хезмәткәрнең каты авыруы уңаеннан | Учреждениенең тиешле комиссиясе (социаль иминият комиссиясе) бәяләмәсе буенча өч айлык хезмәт хакы |
| 5 | Гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә хезмәткәргә китерелгән матди зыянны һәм сәламәтлегенә зыянны каплау максатыннан | Учреждениенең тиешле комиссиясе (социаль иминият комиссиясе) бәяләмәсе буенча өч айлык хезмәт хакы |
| 6 | Хезмәткәрнең ире (хатыны), балалары, ата-анасы вафат булу сәбәпле | Илле мең сум |
| 7 | Хезмәткәрнең ире (хатыны), балалары, ата-анасы каты авыру сәбәпле | Учреждениенең тиешле комиссиясе (социаль иминият комиссиясе) бәяләмәсе буенча егерме мең сум» |

1.4. 2 номерлы кушымтада «Хезмәт хакының айлык ставкасы, аны билгеләү тәртибе һәм шартлары» дигән II бүлекнең 1 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1 нче таблица

**Эшчеләрнең айлык хезмәт хакы ставкалары**

| № т/б | Эшче һөнәрләрнең атамалары | Хезмәт хакының айлык ставкасы, сумнарда | Казан шәһәрендә үзәкләштерелгән бухгалтерлык һәм хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтә торган учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче автомобиль йөртүчеләр өчен айлык хезмәт хакы ставкасына арттыру коэффициенты |
|---|---|---|---|
| 1 | Җыештыручы | 27093 | - |
| 2 | Каравылчы | 27093 | - |
| 3 | Автомобиль йөртүче | 27093 | 1,27 |
| 4 | Вахтер | 27093 | - |
| 5 | Хуҗалык бүлеге мөдире | 27093 | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 | Биналарга хезмәт күрсәтүче эшче | 27093 | - |
| 7 | Урам себерүче | 27093 | -» |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүне бюджет классификациясенең тиешле бүлекләре буенча билгеләнгән тәртиптә каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**